ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 535-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Р.Х. Сөләйманов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 535-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 19 апреле
№ 2437-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
Р.Х. Сөләйманов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1 – 2, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Капиталь ремонт фондын региональ оператор счетында булдырган очракта, торак урыннар милекчеләре капиталь ремонт өчен кертемнәрне региональ операторның үзе яисә өченче зат тарафыннан булдырылган түләү документлары нигезендә Россия Федерациясе Торак кодексында торак урынга һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләргә түләүне кертү өчен билгеләнгән срокларда түлиләр.»;

2) $2^1$ өлештә «түләү билгеләнгән» сүзләрен «түләү Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

Россия Федерациясе Торак кодексының 171 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, капиталь ремонт фондын региональ оператор счетында булдырган очракта, күпфатирлы йортта торак урыннар милекчеләре капиталь ремонт өчен кертемнәрне региональ оператор тарафыннан бирелгән түләү документлары нигезендә торак урынга һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләргә түләүне кертү өчен билгеләнгән срокларда, Россия Федерациясе субъекты законында башкасы билгеләнмәгән булса, түлиләр.

Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру мәсьәләләре һәм капиталь ремонтны үз вакытында ясауны тәэмин итү тәртибе «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 52-ТРЗ номерлы Закон) нигезендә җайга салына.

52-ТРЗ номерлы Законның 8 статьясындагы 2 өлеше нигезендә, капиталь ремонт фондын региональ оператор счетында булдырган очракта, күпфатирлы йортта торак урыннар милекчеләре капиталь ремонт өчен кертемнәрне күпфатирлы йортта торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрне исәпләүче оешма тарафыннан бирелгән түләү документлары нигезендә түлиләр.

Шул ук вакытта, бүгенге көндә Татарстан Республикасында капиталь ремонт өчен кертемнәр җыюны гамәлгә ашыру тәҗрибәсе үзгәрде. 2023 елдан күпфатирлы йортларда торак урыннар милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт өчен кертемнәр күпфатирлы йортларда торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрне исәпләүче оешмалар тарафыннан гына түгел, ә шулай ук исәп-хисап үзәге функциясен башкара торган «Татэнергосбыт» акционер җәмгыяте тарафыннан булдырылган түләү документлары нигезендә түләнә.

Моннан чыгып, Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләре капиталь ремонт өчен кертемнәр җыю эшенең бүгенге көндә фактта булган тәртибен тулы күләмдә исәпкә алмыйлар.

Шуңа бәйле рәвештә әлеге закон проекты белән күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру өлкәсендә хокукый җайга салуны актуальләштерү максатларында, капиталь ремонт өчен кертемнәр җыюны гамәлгә ашыру тәртибе өлешендә барлыкка килгән хокук куллану тәҗрибәсен исәпкә алып, 52-ТРЗ номерлы Законының 8 статьясына тиешле үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.